# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АВАЗ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ

Башкарды: Шабакаев Р.

# Ни өчөн авазлар үзгәрәләр?

- Билгеле булганча, кешеләрнең сөйләме аерым авазларның билгеле бер тәртиптә тезелеп килүе генә түгел, ә аларның бер-берсенә ялганып туктаусыз агышы. Сөйләм агымында нинди аваз белән янәшә булуына, нинди фонетик шартларда килүенә карап, авазлар төрле үзгәрешләр кичерәләр.

# Аваз үзгәрешләренең төрләре

- Сөйләмдәге аваз үзгәрешләрен, ни сәбәпле булуларыннан чыгып, икегә бүлеп карыйлар: **комбинатор** үзгәрешләр, алар авазларның бер-берсенә тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка киләләр; **позицион** аваз үзгәрешләре – авазларның сүздәге урынына, позициясенә мөнәсәбәтле рәвештә туалар.

Комбинатор үзгәрешләр үзләре өч төрле булалар:

- **ассимиляция**, ягъни авазларның бер-берсенә охшашлanулары;
- **аккомодация**, ягъни авазларның бер-берсенә җайлашулары;
- **диссимиляция**, ягъни авазларның охшашсызланулары.

Ассимиляция һәм диссимиляция бертөрле авазлар арасында, ягъни сузыклар белән сузыклар, тартыклар белән тартыклар арасында бара. Аккомодация сузыклар белән тартыклар арасында бара.

Ассимиляцияне иң элек икегә бүлеп карыйлар: сузыклар ассимиляциясе һәм тартыклар ассимиляциясе. Төрле аспектлардан чыгып, ассимиляция тагын түбәндәгечә төркемләнә:
а) тәэсир итешүнең юнәлеше буенча бүленеш: әгәр аваз үзеннән соң килгән авазга тәэсир итеп, аны охшашландырса, – **туры (прогрессив) ассимиляция**(төнлә [төннә]), әгәр үзеннән соң килгән аваз охшашландырса, **кире (регрессив) асимиляция** (унбер [умбер]) дип атала.
б) тәэсир итешүнең нәтиҗәсе буенча бүленеш: әгәр аваз икенче аваз тәэсирендә үз билгеләрен югалтып, үзенә тәэсир иткән авазның билгеләрен алса, – **тулы ассимиляция** (кәтеп [кәтәп]), әгәр бер аваз икенчесенә берәр билгесе белән генә (рәт, ясалу урыны һ.б.) охшашланса, **өлешчә ассимиляция** (алдынгы [а˚лдыңғы]) дип атала.
Тулы ассимиляция вакытында ике бер төрле аваздан бер озын аваз гына да калырга мөмкин (күзсез [күсес]).
в) авазларның янәшәдәшлеге буенча бүленеш: әгәр авазлар янәшә торып тәэсир итешәләр икән – **янәшә (контактлы) ассимиляция**, бер яки берничә аваз аша торып тәэсир итешсәләр, **арадаш (дистактлы) ассимиляция** дип аталалар.

Сузыклар ассимиляциясе ике очракта күзәтелә: сингармонизмга бәйле рәвештә һәм сандхи очракларында.

*Сингармонизм яки сузыклар гармониясе* – барлык төрки телләр өчен дә диярлек характерлы билге. Сингамонизмның ике төре бар – рәт гармониясе һәм ирен гармониясе. Рәт гармониясе – сузыкларның рәт буенча охшашланулары, җайлашулары: әгәр сүзнең беренче иҗегендә алгы рәт сузыгы килсә, алдагы иҗекләрдә дә алгы рәт сузыгы килә, һәм киресенчә.

Түбәндәге очракларда рәт гармониясе сакланмый:

а) алынма сүзләрдә (имтихан, галим, телефон);

б) кушма сүзләрдә (өчаяк,төнбоек,Илдус);

в) кайбер зат алмашлыкларында (миңа, сиңа);

г) кайбер кушымчалар аркасында (көлсу, улмыни).

Татар телендә ирен гармониясе түбәндәгедән гыйбарәт: әгәр сүзнең беренче иҗегендә иренләшкән [о] яки [ө] сузыклары булса, шуннан соңгы иҗекләрдә килүче [ы] яки [е] авазлары иренләшеп, [о], [ө] булып ишетеләләр: ко-лы > [коло], көт-еп > [көтөп]. Шунысын әйтергә кирәк, иренләшү икенче ижектә генә көчле була, алдагы иҗекләрдә иренләшү тәэсире кими. Ә иренләшкән [у] һәм [ү] авазларының мондый ассимилятив үзенчәлекләре булмый.

Этимологик яктан бер тамырга кайтып кала торган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр *сингармоник параллельләр* дип атала: *аз – әз, акрын – әкрен, ана – әни, багланыш – бәйләнеш, чыкылдау – чекелдәү.*

Шулай ук **акустик ассимиляция** күп телләрдә очрый торган аваз үзгәреше. Ул тартыкларның яңгыраулык-саңгыраулык буенча охшашланулары. Ул ике төрле чагылыш таба:

а) саңгырау тартыклар тәэсирендә кайбер яңгырау тартыклар саңгыраулашалар (тозсыз [тоссос], таҗсыз [та˚чсыс]). Моның нәтиҗәсендә кайбер кушымчаларның саңгырау тартыкка тәмамланган сүзләргә өстәлә торган яңа вариантлары барлыкка килгән: -ды/-ты, -га/-ка һ.б.;

б) яңгырау тартыклар тәэсирендә кайбер саңгырау тартыклар яңгыраулашалар. Аеруча [р] сонанты тәэсирендә [п], [к], [қ] тартыкларының саңгыраулашуы күзәтелә (ак – аграк, күп – күбрәк).

Диахроник һәм синхроник ассимиляцияне дә аерып карарага кирәк. **Диахроник ассимиляция** – ул тарихи процесс, аның нәтиҗәсендә, авазлар чиратлашып, яңа кушымчалар барлыкка килгән (урман-лар → урман-нар, күп-дән → күп-тән). Диахроник ассимиляция язуда да чагылыш таба, ә **синхроник ассимиляция** – җанлы сөйләмдә авазларның охшашлануы, сөйләм стилендә орфоэпик норма итеп кабул ителә, ләкин язуда чагылыш тапмый.

**Диссимиляция**, яки охшашсызлану – азрак таралаган күренеш. Күбрәк ул гади сөйләмдә, алынма сүзләрнең әйтелешендә чагылыш таба, татар теле өчен авыррак әйтелешле булган берәр аваз берничә тапкыр кабатланса, ул авазларның берәрсе икенче, җайлырак әйтелешле аваз белән алыштырыла: *директор → дилектор, коридор → кылидур* һ.б.

Диссимиляция, ассимиляциядән аерылмалы буларак, нормалаштырылмаган сөйләмгә (гади сөйләм, диалектлар, балалар һәм өлкәннәр сөйләме) хас һәм орфоэпик норма буларак кабул ителми.

**Аккомодация**, нинди авазлар арасында булуына карап, сузыклар һәм тартыклар аккомодациясенә бүленә. Сузыклар аккомодациясе булганда янәшәдәге тартыклар тәэсирендә, сузыклар шуларның артикуляциясенә җайлашалар; тартыклар аккомодациясе булганда, киресенчә, тартыклар үз янәшәсендәге сузыкларның артикуляциясенә җайлаша. Тартыклар аккомодациясе булганда нечкә сузыклар янында тартыклар палатальләшәләр, ягъни йомшаграк әйтеләләр, а калын сузыклар янында – велярлашалар, ягъни калын итеп әйтеләләр. Мәсәлән, [ба˚р] – [б'әр']. Иренләшкән сузыклар янында тартыклар бераз иренләшебрәк әйтелә. тартыкларга бигрәк тә үзләреннән соң килгән сузыклар нык тәэсир итә: [туп] – [тын].

Сузыклар аккомодациясе турында сөйләгәндә, шуны истә тотырга кирәк: тартыкларның үзләреннән соң килгән сузыкларга тәэсире үзләренә кадәр килгәннәренә тәэсиреннән көчлерәк, ягъни сузыкларның прогрессив аккомодациясе регрессив аккомодациядән көчлерәк: [па˚р], [ма˚л], [чы$^{е}$н].

# Кулланылган әдәбият:

1. Татар грамматикасы: 3 томда. Т. 1. – Казан: Инсан, 1998. – 521б.